# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9-10; Ватаным Татарстан, 2011, 23 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендәге 7 пунктында "ачык акционер җәмгыятьләрне" сүзләреннән соң ", җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрне" сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның 2 өлешендә "дәүләт милкендәге акцияләренең" сүзләреннән соң ", җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталларындагы өлешләренең" сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяның 1 өлешендә "ачык акционер җәмгыятьләр акцияләрен," сүзләреннән соң ", җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталларындагы өлешләрен" сүзләрен өстәргә;

4) 6 статьяның 2 өлешендә "ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләре" сүзләреннән соң ", җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталларындагы өлешләре" сүзләрен өстәргә;

5) 8 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

дәүләт мөлкәтенең исеме һәм аны индивидуальләштерерлек башка белешмәләр (мөлкәтнең характеристикасы);

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру ысулы;

мөлкәтнең башлангыч бәясе;

түләүне кичектерү вакыты (кичектерү рөхсәт ителгән очракта);

дәүләт мөлкәтен бәяләүне уздыру нәтиҗәләре;

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өчен кирәк булган башка белешмәләр.

Унитар предприятиенең мөлкәт комплексы хосусыйлаштырылган очракта дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән шулай ук түбәндәгеләр раслана:

унитар предприятиенең хосусыйлаштырылырга тиешле мөлкәт комплексы составы;

унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлары (шул исәптән аерым хокуклар) исемлеге;

унитар предприятиене үзгәртеп кору юлы белән төзелә торган ачык акционер җәмгыятьнең яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталы күләме;

ачык акционер җәмгыятьнең акцияләре күләме, категорияләре һәм номиналь хакы яисә Татарстан Республикасы өлешенең номиналь хакы.

Унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлары (шул исәптән аерым хокуклары) башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан алына.

Дәүләт предприятиесе ачык акционер җәмгыять итеп үзгәртеп корылган очракта башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы мондый предприятиене хосусыйлаштыру планын төзү турында карар кабул итәргә мөмкин. Хосусыйлаштыру планы формасы башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан раслана.";

б) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслаган көннән алып төзелгән хуҗалык җәмгыятен дәүләт тарафыннан теркәгән көнгә кадәр унитар предприятие башкарма хакимиятнең вәкаләтле органының язма ризалыгыннан башка түбәндәгеләрне башкарырга хокуксыз:";

6) 10 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Ачык акционер җәмгыятьнең акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрен сатканда конкурс шартларын әзерләү һәм раслау тәртибе**";

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Ачык акционер җәмгыятьнең Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге өлешләрен хосусыйлаштыру буенча конкурсның шартлары башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан әзерләнә һәм раслана.

Конкурс шартларында түбәндәгеләр күз алдында тотылырга мөмкин:

эш урыннарының билгеле бер санын саклап калу;

хезмәткәрләрне яңа һөнәргә өйрәтү һәм (яисә) аларның белгечлеген арттыру;

фәнни һәм (яисә) фәнни-техник эшчәнлекне, халыкка социаль-мәдәни, коммуналь-көнкүреш яисә транспорт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган аерым объектларның билгеләнешен үзгәртүне һәм (яисә) күрсәтелгән объектлардан файдалануны туктатуны чикләү;

мәдәни мирас объектларына, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларына карата реставрация, ремонт һәм башка эшләр башкару.

Конкурс шартларында икътисадый нигезләү, аларны үтәү вакытлары, мондый шартларны үтәү конкурсында җиңүчене раслау тәртибе булырга тиеш. Конкурс шартлары үзгәртелмәскә тиеш.

Конкурс шартларының күрсәтелгән исемлеге хәлиткеч була.";

7) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. **Акционер җәмгыятьләрнең Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге үзләренә милек хокукы күчкәнчегә кадәр конкурста сату объектлары булып торучы акцияләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталларындагы Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге үзләренә милек хокукы күчкәнчегә кадәр конкурста сату объектлары булып торучы өлешләре буенча тавыш бирү тәртибе**

Конкурста җиңүче ачык акционер җәмгыятьнең конкурста сатып алынган акцияләренә, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы конкурста сатып алынган өлешенә милек хокукы аңа күчкәнчегә кадәр әлеге җәмгыятьләрнең идарә органнарында күрсәтелгән акцияләр, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше буенча үз теләге белән тавыш бирә, моңа түбәндәге мәсьәләләр буенча тавыш бирү керми:

хуҗалык җәмгыятенең гамәлгә кую документларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

әгәр мондый мөлкәтнең хакы хуҗалык җәмгыятенең устав капиталыннан биш процентка артып китсә яисә хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән илле мең тапкырдан артып китсә, хуҗалык җәмгыяте мөлкәтен читләштерү, залогка салу, арендага бирү һәм читләштерүгә китерерлек башка гамәлләр кылу;

хуҗалык җәмгыятенең күчемсез мөлкәтен залогка салу һәм читләштерү;

хуҗалык җәмгыятенең саф активлары хакының биш процентыннан да артыграк күләмдә кредит алу;

хуҗалык оешмаларын, ширкәтләрен гамәлгә кую;

ачык акционер җәмгыять акцияләренә конвертацияләнми торган кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе;

хуҗалык җәмгыятенең еллык хисабын, бухгалтерлык балансын, табышын һәм зыяннары исәпләрен раслау, шулай ук аның табышын һәм зыяннарын бүлешү.

Бу мәсьәләләр буенча тавыш бирүне конкурста җиңүче үзенең тавыш биргәндәге позициясен башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы белән язма рәвештә килештергәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

Хуҗалык җәмгыятен үзгәртеп кору яисә бетерү мәсьәләсе буенча конкурста җиңүче тавыш бирү хокукына ия түгел.";

8) 12 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"19 статья. **Акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган һәм дәүләт яисә муниципаль унитар предприятиеләргә, дәүләт яисә муниципаль учреждениеләргә беркетелмәгән ачык акционер җәмгыятьләр, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең хокукый хәле үзенчәлекләре**

1. Акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган һәм дәүләт унитар предприятиеләренә йә дәүләт учреждениеләренә беркетелмәгән ачык акционер җәмгыятьләрнең акционерлары, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең катнашучылары хокукларын Татарстан Республикасы исеменнән башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы гамәлгә ашыра.

2. Ачык акционер җәмгыятьләрнең, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең идарә органнарында һәм ревизия комиссияләрендә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен чагылдыручы вәкилләр дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук башка затлар булырга мөмкин.

3. Хосусыйлаштыру барышында төзелгән, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган ачык акционер җәмгыятьләр, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр белән идарә итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Әгәр ачык акционер җәмгыятьнең дәүләт унитар предприятиеләренә, дәүләт учреждениеләренә беркетелмәгән 100 процент акцияләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы дәүләт унитар предприятиеләренә, дәүләт учреждениеләренә беркетелмәгән 100 процент өлеше Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булса, җәмгыятьнең югары идарә органы вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы гамәлгә ашыра. Акционерларның гомуми җыелышын, җәмгыятьтә катнашучыларның гомуми җыелышын әзерләү һәм үткәрү буенча "Акционер җәмгыятьләр турында" 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында" 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль законда каралган процедуралар, акционерларның еллык гомуми җыелышын, җәмгыятьтә катнашучыларның еллык гомуми җыелышын үткәрү срокларына кагылышлы нигезләмәләрдән тыш, кулланылмый.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 73-ТРЗ